**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

# КАРАР

07.12.2020 № 596

**2020 елның 6 декабрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе 2020 елның 6 декабрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлегенә 17710 референдумда катнашучы кертелгән, референдумда тавыш бирүдә катнашканнар саны 9874, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегендәге катнашучыларның 55,75%ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен референдумда катнашучыларның 7021е (71,11%) тавыш бирде, бу референдумда тавыш бирүдә катнашканнарның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; "Юк" позициясе өчен референдумда катнашучыларның 2836 ы тавыш бирде, бу 28,72% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елның 6 декабрендә булган референдумны үткәрелде, референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. “2021 елда «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?”

1. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам утларын алыштыру һәм урнаштыру, изоляцияләнгән чыбыклар сузу һәм урам утлары баганаларын утырту:

-Арча шәһәре: Юл тыкрыгы; КФҮтән Г. Салихов урамына кадәр ара; Г. Ахунов урамы; Тимер Юл урамы; М. Галәү урамы; Ватан урамы; Фабрика урамы; Пионер ур., Май тыкрыгы, М. Горький ур., Зур ур., Наратлык ур.;
Астрономнар урамы; Бирәзә тыкрыгы; Г.Салихов урамы; Коммуна урамы; «Казан-Малмыж» автомобиль юлыннан Ф. Әмирхан урамына кадәр квартал; Кәримов урамы; Ямашев урамы.
- Төбәк-Чокырча авылы, Бакча урамы.
- каты көнкүреш һәм коммуналь калдыклар өчен контейнер һәм бункер мәйданчыкларын киртәләп алу һәм аларга керү юллары ясау:
- Арча ш.: Совет мәйданы; Г.Тукай урамы (1 нче квартал); С. Сәйдәшев урамы; Коммуна урамы; Кызыл Бистә урамы; Түбән урам- 1; Түбән урам-2; Түбән урам-3; Тимер юл урамы; Ватан урамы; Фабрика урамы; Көнбатыш тыкрыгы; Кояшлы урамы.
- Иске Айван авылы, Түбән ур., Югары ур.
- материаллар сатып алу һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү:
- Арча шәһәре, Тау өсте ур.;
- Васильева Божа, Кыр ур.;
- Иске Айван авылы, Түбән ур.
- каты көнкүреш һәм коммуналь калдыкларның контейнер һәм бункер мәйданчыкларын киртәләү һәм аларга килү юллары ясау:
- Арча ш.: Совет мәйданы; Г.Тукай урамы (1 нче квартал юлы); С. Сәйдәшев урамы; Коммуна урамы; Кызыл Бистә урамы; Түбән урам- 1; Түбән урамы-2; Түбән урам-3; Тимер юл урамы; Ватан урамы; Фабрика урамы; Көнбатыш тыкрыгы; Кояшлы урамы.
- Иске Айван авылы: Түбән урам; Югары урам.
- материаллар сатып алу һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү:
- Арча шәһәре, Тау өсте ур.;
- Васильева Божа, Кыр ур.;
- Иске Айван авылы, Түбән ур.

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге:
- юлларның нигезен салу һәм вак таш җәю:
- Арча ш.: маршал Жуков ур., (15тән 17нче йортка кадәр); Күпер урамы (31нче йортка керү юлы); Комсомол урамы (78нче йорт); Комсомол урамы (АЗС артында); Кәримов урамыннан Ф. Мансуров урамына кадәр квартал; Ф. Мансуров урамы; Себер тракты ур.; Г. Салихов ур.; Сибгатуллин урамыннан Маяковский урамына кадәр; Сибгатуллин урамыннан Яшьләр урамына кадәр квартал ; Сибгатуллин урамыннан Космонавтлар урамына кадәр 2 нче квартал; Бирәзә урамыннан К. Тинчурин урамына кадәр квартал; Хезмәт урамы, 2а, 2б йорт; Тирәк урамы; Болын урамы; Урманлы тыкрыгы.
- Зур Бирәзә авылы: Арча-Олы Әтнә автомобиль юлыннан зиратка кадәр дамба; Үзәк урамнан Г. Тукай урамына кадәр квартал;

- Күпербаш авылы: Мәктәп урамы; Яр буе урамы; Мичурин урамыннан алып Яр буе урамына кадәр квартал;
- Төбәк-Чокырча авылы: Дан ур., Гагарин ур.;
- Айван авылы: С. Садыйкова урамы, Түбән урамнан Югары урамга кадәр квартал;
- юлларның өслегеН вак таш белән каплау:
- Арча шәһәре, Бирәзә ур.;
- Васильев Божа авылы, Магистраль урамы;
- Иске Айван авылы, Түбән ур., Югары ур.

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- 11 данә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:
- Арча ш.: Н. Сафин ур., Шаляпин ур., Зәйнуллин ур., Ш. Күлтәси; Агрономнар урамы; Җиңү урамы; М.Гафури урамы; Маяковский урамы; Яшьләр урамы; Островский урамы; Пионер урамы.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Арча шәһәре Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә" дигән сорау буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырырга, әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л.И. Нурмиева